**Казанский (Приволжский) федеральный университет**
**Институт социально-философских наук и массовых коммуникаций**
**Высшая школа журналистики и медиакоммуникаций**
**Центр детского творчества пос. Дербышки Советского района города Казани**

# СОВРЕМЕННОЕ МЕДИАПРОСТРАНСТВО И ШКОЛА: ТОЧКИ СОПРИКОСНОВЕНИЯ

**Материалы научно-практической конференции**

**Казань**
**2025**

**УДК 070**

**Научный редактор:**
доктор филологических наук, профессор **В. З. Гарифуллин**

**Ответственные редакторы:**
кандидат филологических наук, доцент **Р. Л. Зайни**
кандидат филологических наук **А. А. Гусейнова**

Современное медиапространство и школа: точки соприкосновения. Материалы научно-практической конференции. – Казань, 2025. – 275 с.

В сборнике представлены материалы и научные статьи по итогам VII всероссийской научно-практической конференции «Современное медиапространство и школа: точки соприкосновения» (г. Казань, 4 декабря 2025 г.).

# СОДЕРЖАНИЕ


***XXI гасырда татар журналистикасы һәм әдәбияты* 6**
***Татарская журналистика и литература в XXI веке***

Гайфуллина Л.Х., Шакирова И.М. «Мәгариф» журналы - укытучыларның остазы **6**

Галиева Р.М. «Казан утлары» журналының татар укучысын тәрбияләүдәге роле **13**

Гарифуллин В.З. Татар телендә педагогик басмалар: үсеш этаплары **17**

Гусейнова А.А. Роль татарской журналистики в развитии и сохранении национального сознания и языка **25**

Зәйни Р.Л. Балалар журналларының интернетта эшләү үзенчәлекләре **34**

Исмәгыйлова А.А. «Арча хәбәрләре» газетасы – районыбыз елъязмасы **40**

Мокыймова Г.Ф. Хәсән Туфан шигъриятендә көчле лирик һәм психологик элементларның чагылышы **48**

Сабирова Л.Р., Паташина А.Р. Особенности продвижения личного бренда журналиста в социальных сетях **51**

Талыпова Л.Н. Тәлгат Галиуллинның «Ана корт» повестендә хатын-кыз образлары **58**

Юнысова Э.Ф. Нәбирә Гыйматдинованың «Сихерче» повестендә хатын кыз образлары **62**

Ягудина Р.Р. Татар журналистикасында милли мәдәниятне яктырту **66**

***Мәктәптә һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә журналист һөнәрен популярлаштыру* 70**
***Популяризация профессии журналиста в школах и учреждениях дополнительного образования***

Габделвәлиева Р.Н., Гафарова Г.Г. Туган телне укытуда вакытлы матбугат куллануның әһәмияте **70**

Ганиева А.И. Мәктәп дулкынында **73**

Лотфуллина Л.Ә. «Максуди FM» яшь журналистлар иҗат төркеме эшчәнлеге **77**

Мостафина Ә.В. Мәктәптә матбугатны популярлаштыру чаралары **82**

Мухаметова Ф.Г. Развитие медиакомпетенций школьников на родном языке в контексте интеграции с вузовской средой **86**

Хафизова З.М. «Хыял» әдәби-иҗат берләшмәсенең иҗат үрнәкләре **90**

***Балаларның киберкуркынычсызлыгын тәэмин итү чаралары* 97**
***Средства обеспечения кибербезопасности детей***

Ваганова А.И. Киберкуркынычсызлык безнең кулда **97**

Валитова И.Н. Основы кибербезопасности: защита от угроз **100**

Гәрәева Г.А. Киберкуркынычсызлык кагыйдәләре **108**

19. Хангилдин В.Н. Татар теле культурасының кайбер мәсьәләләре. Казан: Тат. кит. нәшр., 1976. 96 б.

20. Хәсән Сарьян. Уеңны уйдырып сал...: Тел, әдәби осталык турында мәкаләләр. Казан: Тат.кит.нәшр., 1977. 140 б.

21. Юсупов Р.А. Әдәп башы – тел: Икетеллелек шартларында дөрес сөйләм мәсьәләләре. Казан: КДПУ, 2000. 218 б.; Юсупов Р.А. Мәгълүмат чаралары теле һәм сөйләм культурасы. Казан: ТДГПУ, 2007. 193 б.

## БАЛАЛАР ЖУРНАЛЛАРЫНЫҢ ИНТЕРНЕТТА ЭШЛӘҮ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***Зәйни Резеда Локман кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, доцент,*
*Казан федераль университетының милли һәм глобаль медиа чаралары кафедрасы доценты*

Кеше шәхес буларак балачакта формалаша. Тәрбия һәм белем бирү процессында яшь укучыларга юнәлдерелгән массакүләм мәгълүмат чараларын куллану балалар үсеше өчен мөһим. Балалар басмалары аудиториясенең яшь үзенчәлекләрен белү әлеге аудиториянең, бу очракта – балаларның, кызыксынуларын һәм ихтыяҗларын канәгатьләндерергә ярдәм итә. Әмма шуны истә тоту мөһим: бүгенге балалар моңа кадәр килгән буын балаларыннан бик нык аерыла. Аларның табигый сәләтләре, дөньяны кабул итүләре һәм максатлары бөтенләй төрле. Алар текстны азрак укый, ләкин күбрәк мәгълүматны фото, видео һәм аудио аша ала.

Бүгенге көндә Татартснда балалар өчен татар телендә өч журнал чыга: мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен – «Салават күпере», кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен - «Сабантуй», яшүсмерләр өчен – «Ялкын».

Барлык өч басманың да гамәлгә куючысы бер – «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте. Журналлар Казанда айга бер тапкыр чыга. Барлык өч журналның да Татарстан Республикасында һәм Россиядә массакүләм мәгълүмат чаралары үсеше этаплары белән бәйле зур тарихы бар.

«Ялкын « - 48 биттән торган төсле иллюстрацияле айлык басма. 12 яшьтән өлкәнрәк балалар өчен юнәлдерелгән. Басма тарихы XX гасырның ерак 20нче елларына барып тоташа. «Татарстан» газетасында Муса Җәлилнең 9-14 яшьлек балалар өчен махсус журнал чыгарырга кирәклеге турындагы мәкаләсе басылып чыккач, шул ук елның март аенда Мәскәүдә «Кечкенә иптәшләр» дигән балалар журналы чыга башлый. Журнал баштан ук гарәп графикасында басыла, 1928 елда латин графикасына күчә һәм «Октябрь баласы» дип атала башлый. 1933 елда журнал Казанга күчеп килә һәм «Пионер каләме» дигән исем ала. 1941 елда, Бөек Ватан сугышы башлангач, журнал басылудан туктап тора, бары тик 1952 елда гына ул «Пионер» исеме астында яңадан туа. Ә 1957 елда, илдә «Пионер» исемле журналлар саны арту сәбәпле, журналның исеме үзгәртелә һәм ул бүгенге көнгә кадәр «Ялкын»исемен йөртә.

Журналның заманга туры китереп эшләнгән һәрбер саны урта һәм өлкән яшьтәге мәктәп балалары тормышының барлык аспектларына кагылышлы кызыклы материалларны үз эченә ала, бу уку да, ял да, сыйныфташлары, ата-аналар, укытучылар белән мөнәсәбәтләр дә. Журнал даими рәвештә мәктәпләрдә очрашулар, мастер-класслар оештыра, балаларның иҗади эшләрен бастыра. Журналда мәдәният, сәнгать өлкәсеннән, яшьләрнең кумирлары турында язмалар күп.

Карала торган икенче журнал – «Сабантуй» – 36 биттән торган төсле иллюстрацияле айлык басма. 6 яшьтән зуррак балалар өчен билгеләнгән. Аның тарихы да XX йөзнең 20нче елларыннан башлана: 1924 елда «Яшь ленинчы» газетасының беренче саны дөнья күрә. Газета битләрендә: «Газета барлык пионерларга һәм эшче-крестьян балаларына ничек яхшырак эшләргә, ничек берләшергә, ничек пионер сафларына басарга икәнен күрсәтәчәк», – дип язганнар ул чакта.

Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Фатих Кәрим, Әмирхан Еникиеники басманың беренче авторларыннан була. Бөек Ватан сугышы башланганнан соң, газета шулай ук чыгудан туктый, әмма «Кызыл Татарстан» газетасында «Пионер бите» рубрикасы рәвешендә яшәвен дәвам итә. 1961 елда яңадан ачыла, ә 1991 елда «Сабантуй» исеменә үзгәртелә. 2014 елдан «Сабантуй» газетасы ребрендинг кичерде һәм яңа форматтагы төсле журналга әверелде.

Карала торган өченче журнал – «Салават күпере», алдагы ике журналдан аермалы буларак, 30 елдан артык чыга. Шулай ук төсле иллюстрацияле айлык басма, 16 биттән тора. Яшь чикләүләре юк. Журналның исеме бәхетле һәм кайгысыз балачакны символлаштыра. Журнал беркадәр вакыт пакетка тутырылган килеш чыкты, анда һәр бала үзенә бүләк таба ала иде. Бүген журналның битләре сәнгатьчә кисеп чыгарыла, ягъни вырубка кулланыла (мәсәлән, песи силуэты сайланган). Болай эшләү Татарстан Республикасы массакүләм мәгълүмат чаралары арасында оригиналь күренеш булып тора. Журнал редакциясенең тагын бер стратегик адымы – ул да булса, төрле конкурслар һәм акцияләр уздыру юлы белән укучылар кызыксынуын даими активлаштыру. Бүген бу журнал битләрендә балалар яраткан шөгыльләре, хыяллары һәм фикерләре белән уртаклаша; туган телләрендә кызыклы шигырьләр, әкиятләр, фоторепортажлар, сканвордлар, комикслар, анекдотлар белән таныша. Шунысы уникаль, журнал беренче саннарыннан ук күпсанлы талантлы рәссамнар белән уңышлы һәм нәтиҗәле хезмәттәшлек итә, чөнки кече яшьтәге балалар өчен оригиналь рәсемнәрсез матур журнал чыгару мөмкин түгел.

Югарыда әйтелгәнчә, хәзерге балалар элекке буыннардан аерыла. Заман рухына һәм максатчан аудитория ихтыяҗларына туры килсен өчен, балалар өчен заманча татар басма журналлары да мультимедиа форматына күчә.

Аудиторияне колачлау өчен сайтта шул басма санда чыккан материалларны күчереп бастырып, сайтны басманың көзгедәге чагылышына гына әйләндерү һич җитми. Журнал редакциясе, сайтлар һәм социаль челтәрләр урнашкан платформаларның билгеле бер йогынтысын исәпкә алып, сайт һәм социаль челтәрләр өчен төрле язмалар булдыруга дөрес якын килергә тиеш. «Ялкын», «Сабантуй» һәм «Салават күпере» журналларының социаль челтәрләрдәге аккаунтларының эчтәлеген анализлау шундый нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә: аларда, нигездә, мәгълүмати текст кулланыла, ләкин ул еш кына ул текст өндәмәгә (чарага чакыру, реклама, анонс) яки балалар яки аларның ата-аналары белән аралашуны формалаштыручы контактлы текстка (сораштырулар, мастер-класслар) әйләнә.

«Салават күпере» журналындагы дидактик уеннар, наклейкалар һәм стикерлар, журнал битендә үк аның сайтында тиешле битне ачарга мөмкинлек бирә торган QR-кодлар урнаштыру – болар барысы да замана балалары өчен кызыклы. YouTube каналындагы, сылтамалар буенча кереп карарга мөмкин булган татар телендәге видеороликлар нибары 2-3 минут дәвам итә, ләкин алар татарча язма тыңларга, өстәмә мәгълүмат алырга мөмкинлек бирә. Бала өчен бу кызык, мавыктыргыч. QR-кодлар басманың басма вариантында актив кулланыла, әйтергә кирәк, алар хәтта журнал тышлыгына да урнаштырыла.

Журналның басма версиясе битләрендә конкрет авторның шигырьләре басылган очракта, янәшәсенә QR-код урнаштырыла, аның аша каналга кереп, бу шигырьләрне автор укуында тыңларга мөмкин.

Яңа идеяләрдән шуны билгеләп үтәргә була: «Салават күпере» журналының декабрь саны адвент-календарь формасында да чыкты. Бер яктан, адвент идеясе татар, мөселман баласы өчен ят, чөнки адвент – Христос динендә Раштуа алды вакыты атамасы ул. Әмма бу сүз хәзер киңрәк мәгънәдә, теләсә кайсы бәйрәмне көтү вакытын аңлатып, бөтен дөньяда аерым бер конфессия белән бәйләмичә генә кулланыла, шуңа күрә журнал аны үзенең яңа ел алды санында кулланырга карар кылган. Журналдагы Адвент-календарь нәниләр өчен биремнәргә бай: мәсәлән, уенчык-чыршы яса, Кыш Бабайга хат яз һәм аның турында җыр җырла, тәмле Яңа ел печеньесы пешер, тәрәзәләрне кар бөртекләре белән бизә.

Журнал интернет кушымтасы аша мастер-класслар (дәресләр) оештырды. Дәресләр атна саен чәршәмбе көннәрендә онлайн уза: мәсәлән, балалар Әниләр һәм Кыш Бабай көненә открыткалар, песнәк рәсеме ясадылар.

«СалаваТик» проекты да журналның интернеттагы эшчәнлеге үрнәге булып тора. Әлеге проект кысаларында 6 баладан торган төркемнәр оештырыла. Алар белән видеоклиплар яздырыла. Балалар татар халык җырларын яки татар телендә иҗат ителгән балалар җырларын башкаралар. Бу клипларны балалар буш вакытларында карый, шулай ук аларны тәрбиячеләр һәм укытучылар балалар бакчасында һәм башлангыч мәктәптә файдалана ала. Журнал әледән-әле балалар җырларының ноталарын һәм сүзләрен бастыра.

«Сабантуй» журналына күчсәк, аның максатчан аудиториясе - өлкәнрәк балалар. Димәк, журнал битләрендә мәгълүмат тезислар рәвешендә бирелгән, ә иң зур басым фото- һәм видеоконтентка ясалган. Һәр биттә урнаштырылган QR-код аркылы смартфон ярдәмендә сайтка кереп, видео карарга мөмкин. Шул рәвешле журнал хәзерге балалар куйган таләпләргә туры килергә тырыша.

«Ялкын» журналының YouTube сайтында уникаль каналы бар, аңа сылтама журнал сайтының төп битендә урнаштырылган. Канал 6 ел элек барлыкка килгән һәм, «Әйдә, киттек!», «Лимон», «Бик матур», «Интервью» кебек сәхифәләр ярдәмендә караучылар рәтен арттыруын дәвам итә. «Әйдә, киттек!» сәхифәсендә алып баручы үзенең республика буенча сәяхәтләре яки эш командировкалары турында мавыктыргыч итеп сөйли, кызыклы урыннар һәм кешеләр белән таныштыра. «Лимон « - дөньяда барган вакыйгаларны билгеле бер күзлектән аңлатырга тырышкан рубрика. «Бик матур» аеруча еш чыга, чөнки биредә яшьләр өчен актуаль темалар - мода, стиль турында сөйлиләр, дөрес киенергә өйрәтәләр. Һәм, ниһаять, «Интервью» – кабатланмас шәхесләр, кызыклы кешеләр белән мавыктыргыч әңгәмәләр өчен кунак бүлмәсе ул.

Барлык өч журналның да «ВКонтакте», «Одноклассники», «Телеграм» социаль челтәрләрендә аккаунтлары бар. Мәсәлән, «Салават күпере» журналының «ВКонтакте» социаль челтәрендәге бите актив алып барыла, көн саен видео, фото яки иллюстрацияләр белән хәбәрләр урнаштырыла. Хәбәрләр төрледән-төрле: бу zoom дәресләре турында мәгълүмат та, элеге дәресләрнең рәсемнәр рәвешендәге нәтиҗәләре дә, басманың яңа санын тәкъдим итү дә, шулай ук «СалаваТик» проектының видеоязмалары да, мәктәпләрдән, балалар бакчаларыннан күпсанлы репортажлар да. Бергәлектә 5 меңнән артык язылучы бар, һәр постны, уртача алганда, 100 дән 1000 гә кадәр кеше карый.

«Сабантуй» журналының «Вконтакте» социаль челтәрендәге битендә 9 меңгә якын язылучы бар. Һәр хәбәрне, уртача алганда, 100 дән берничә меңгә кадәр кеше карый. Биттә - видеолар, кул эшләнмәләре турында мастер-класслар (мәсәлән, футболканы тай-дай стилендә бизәргә өйрәтәләр), шулай ук репортажлар, очрашулар, фотолар һәм күпсанлы конкурсларда җиңүчеләрнең

исемнәре, журналны әзерләү барышы, аның эчке кухнясы турында видеолар.

Социаль челтәрдәге битләрдә журналлар ясалма фәһем ясаган рәсемнәрне еш кулланалар, бу битләрне тагын да матурайтырга һәм эшне арзанайтырга ярдәм итә.

Социаль челтәрләр, дуслар һәм туганнар белән аралашу чарасы буларак оештырылуга карамастан, бүгенге көндә өлешчә гаммәви мәгълүмат чаралары ролен дә үти алалар (гәрчә аларның гаммәви мәгълүмат чаралары булу-булмавы турындагы сорауга әле ахыргача җавап бирелмәгән булса да), шулай ук алар гамәлдәге гаммәви мәгълүмат чараларына карата кызыксыну тудыру коралы булып хезмәт итә алалар.

Шуңа күрә кайчакта әлеге журналларның социаль челтәрләрендәге постлары, тулы кыйммәтле текстларга караганда, анонсларны, лидларны хәтерләтергә мөмкин, шул рәвешле алар без сөйләгән гаммәви мәгълүмат чараларының аудиториясе һәм сайты арасында арадашчы булып торалар.

Социаль челтәрләр мәгълүматны урнаштыручылар өчен дә, аны кулланучылар өчен дә уңайлы, чөнки алар интернет-журналистиканың гипертекстуальлек, мультимедиалылык һәм интерактивлык дигән өч сыйфатына ия. Шуңа күрә бүгенге көндә ГМЧ аудиториясенең үзенә җәлеп итеп торган социаль челтәрләргә китүен, ягъни газета-журналларга караганда, социаль челтәрләрне генә укуын, каравын билгеләп үтми мөмкин түгел. Ә татар телле балалар журналлары, күргәнебезчә, аудитория артыннан иярә, шунда кызыклы контент тудыра, ә бу исә басма рәвештә чыгучы журналның, аның электрон версиясенең һәм социаль челтәрләрдәге битләренең, бергә кушылып, нәтиҗәле эшләвенә китерә.